Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 16 (692) 23 август 2019 ел (1440, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

# Хаҗлары кабул булсын!



Хаҗ сәфәренә быел Татарстаннан 1800 кеше юл тоткан иде. Аларга быел да, узган елдагы кебек үк, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җибәрелгән 20 табиб хезмәт күрсәтте. Табибларның ким дигәндә биш еллык хезмәт тәҗрибәсенә һәм җирле пациентлар тарафыннан яхшы бәяләмәгә ия булулары шарт итеп куелды. Хаҗ дәвамында Мәккәдә медицина ярдәме күрсәтү Татарстан хаҗилары яшәгән өч кунакханәдә тәүлек дәвамында оештырылды. Сәфәр өчен «ДУМ РТ Хаҗ» җитәкчелеге кардиограф, глюкометр, тонометр һәм башка кирәкле медицина җиһазларын җитәрлек санда алдан хәстәрләп, Мәккәгә алып килде.

Казаннан килгәндә 10-15 градус җылы булса, биредәге 40 градус эсселек иң беренче чиратта хроник авырулары булган кешеләргә йогынты ясады. Климат үзгәрүчәнлеген авыр кичергән хаҗилар да даими рәвештә табиблар күзәтүендә булды. Табиблар, авыруны дәвалауга караганда аны булдырмый калу җиңелрәк, дигән принциптан чыгып эш йөртте һәм хаҗиларга үзләренең киңәшләрен һәрдаим җиткереп торды: салкын су эчмәскә, кондиционердан чамасыз файдаланмаска, ихрамнан тыш вакытта аякка җылы носки яки аяк киеме киярга.

Аллаһыга шөкер, хаҗ исән-имин узды, татарстанлылар арасында зыян күрүчеләр булмады. Төркем җитәкчеләре дә хаҗиларның иминлеген кайгырту өчен бар тырышлыгын куйды, бәрелү, сыну, тапталу очраклары күзәтелмәде.

Хаҗдан кайтучыларны Казан аэропортында каршы алганда, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, хаҗиларны котлап кына калмыйча, шушы олы сәфәрнең әһәмиятен дә аңлатып китте: "Хаҗ кылган кеше яңадан туган кебек була: ул үзенең гөнаһ капчыкларын бушата, күңелен чистартып кайта. Хәзер инде хәрәмнән сакланып яшәргә кирәк. Раббыбыз хаҗларыгызны һәм корбаннарыгызны кабул итсен. Аллаһы Тәгалә безгә Аның җәннәтләрендә бүгенгедәй шат булып очрашырга насыйп әйләсә иде".

**(ТР МДН сайтыннан)**

# Олыга да, кечегә дә бәйрәм



Күптән түгел Ислам диненең иң күркәм бәйрәмнәренең берсе – Корбан гаете узды. Чаллы шәһәре мәчетләрендә бәйрәм вәгазьләре иртәнге сәгать 5тә башланды. Намазга килгән халык мәчеткә сыеп бетмәү сәбәпле, кайберәүләргә намазны урамда укырга туры килде. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин гает намазын "Нур-Ихлас" мәчетендә укытты. Гает намазы тәмамланганнан соң, иртәнге сәгать алтыдан башлап, үзәкләштерелгән корбан чалу мәйданчыгы изге йоланы үтәргә теләүчеләрне кабул итә башлады. Корбан чалу өч көн дәвамында барды.

Сидоровка бистәсендә урнашкан бу мәйданчыкта корбан чалучылар су, элеп тунау урыннары белән тәэмин ителгән, ветеринария контроле, ГИБДД, полиция посты эшли, мал калдыклары җыеп барыла, намаз бүлмәсе җиһазланган. Мал чалу һәм тунау хезмәте күрсәтелә. Мохтаҗлар һәм "Ак мәчет" мәдрәсәсе өчен корбан ите җыю оештырылган. Мохтаҗларга корбан итен җыю һәм тарату эшчәнлеге "Ихсан" хәйрия фонды тарафыннан башкарыла. Бу елны корбан чалу мәйданчыгын бәйрәмгә әзерләү дә шушы фонд ярдәме белән эшләнде. Дини йоланы үтәргә теләүчеләргә уңайлы булсын өчен махсус ярдәмчеләр, корбан чалучылар төркеме җыелды һәм укытылды. Шәһәр мэры Наил Гамбәр улы, бәйрәм намазыннан сон, үзе дә шушы мәйданчыкка килде һәм корбан чалуга әзерлекне яхшы дип бәяләде.

Шулай ук шәһәребезнең кайбер мәчетләрендә Корбан гаетенә багышланган чаралар булып үтте. "Нур-Ихлас" мәчетендә гадәттәгечә балалар өчен бәйрәм, ә "Туфан" мәчетендә корбан ашы үткәрелде. Балалар өчен булдырылган чарада төрле уеннар, викториналар уздырылды. Ярышларда җиңгән балаларга "савап лар" тапшырылды. Соңрак ул "савапларны" балалар мәчет территориясендә урнаштырылган аттракционнарга куллана яки "Савапмаркет"та бүләккә алыштыра алдылар. Корбан гаете шәһәребездә бик матур рәвештә узды.

Бәйрәм узгач, "Ихлас" мәчетендә җыелыш үткәрелде. Ул Корбан бәйрәме көннәрендә Сидоровка бистәсендә урнашкан корбан чалу мәйданчыгында башкарылган эшчәнлеккә нәтиҗә ясау мәҗлесе иде. Әңгәмә барышында мәчет имам-хатыйбы Илгиз хәзрәт Сөнгатуллин корбан чалучылар һәм волонтерлар өчен алып барылган укыту, аның нәтиҗәләре һәм мәйданчыкта килеп чыккан авырлыклар турында үз фикерләре белән уртаклашты. Шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин "Ихсан" фонды тарафыннан башкарылган эшкә яхшы дип бәя бирде. Киләсе елларны да шәһәребездә корбан чалу йоласын шулай нәтиҗәле рәвештә үткәрүләрен теләде.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

# ТР МДН хәбәр итә

Корбан бәйрәме көннәрендә «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларга социаль азык-төлек ярдәме күрсәтте. Мөфтияттән корбан итләре алучылар арасында – азкеремле һәм күпбалалы гаиләләр, инвалидлар, ятимнәр, ялгыз өлкәннәр, шулай ук республиканың социаль учреждениеләре: хоспислар, интернатлар, мәдрәсәләр, хәйрия фондлары бар. Бәйрәмнең беренче көнендә бәйрәм күчтәнәчен – 1,5 тонна күләмендә корбан итен 500 мохтаҗ кешегә өләштеләр. Икенче көнне тагын 650 гаиләне 2 тонна корбан ите белән тәэмин иттеләр. Моннан тыш, 2 тонна итне республиканың социаль учреждениеләренә озаттылар. Әлеге оешмалар арасында беренче балалар хосписы, А.Вавилова исемендәге Казан хосписы, акыл үсешендә тайпылышлар булган балалар өчен 1 нче мәктәп-интернат, "Диабетсыз тормыш" Идел буе профилактика үзәге, "Восхождение" инвалидларны тернәкләндерү үзәге, Яшел үзән шәһәренең психоневрологик диспансеры, Инвалид балаларның әти-әниләренең "Забота" тәбәкара иҗтимагый оешмасы. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: ит корбан чалган мөселманнардан да килеп ирешә.

# "Хәләл Үзәк"тә ярминкә



Чаллының Яңа шәһәрендә урнашкан "Хәләл Үзәк"тә Корбан бәйрәменә багышланган Хәләл ярминкә узды. Ярминкәдә мөселманнар үзләре үк җитештергән эшләнмәләр белән сату иттеләр. Һәркемгә бәйрәм өстәленә куярга пешкән ризыклар, казылык, балык, татлы чәкчәк, пироглар сатып алу мөмкинлеге булды. Көндәлек кирәк-ярак товарларын да сату оештырылды.

# Игелек кылырга теләсәң...




Чаллының "Ихсан" хәйрия фонды "Мәктәпкә әзерләнергә булыш" дигән акция оештыра. Теләге булган һәркем аның игелекле эшләрендә катнаша ала. Азкеремле, күпбалалы гаиләдә тәрбияләнүче балаларга, ятим сабыйларга яңа уку елына әзерләнергә булышырга теләүчеләр фондның Чаллы шәһәре, Гвардейская, 9а йортында урнашкан офисына мөрәҗәгать итә ала.

# Аллаһтан башка, гыйбадәткә лаеклы зат юк

*Әй, иман китергән бәндәләр, Аллаһка тәкъва булыгыз (тәкъвалык ул – гыйлемгә таянып Аллаһ ризалыгы өчен изге гамәлләр кылу, һәм Аллаһның газабыннан куркып, гөнаһларны калдыру) һәм белегез: Аллаһ Тәгалә безне барыбызны да күрә, бар әйткән сүзләребезне ишетә, чөнки Раббыбыз бар нәрсәне күрүче һәм ишетүчедер.*

Дөреслектә, сүзләрнең иң бөеге - ул "Ләә Иләәһә илләә Аллаһ" кәлимәседер. Шушы кәлимәне торгызу өчен җиде кат күк белән җир, бөтен мәхлүклар юктан бар ителде һәм китаплар иңде һәм Аллаһның рәсүлләре җибәрелде һәм җәннәт белән җәһәннәм барлыкка килде. Кем дә кем "Ләә Иләәһә илләә Аллаһ" кәлимәсен әйтсә, һәм аның буенча яшәсә, шул җәннәт әһелләреннән булыр. Ә кем ул кәлимәдән баш тартса, тәкәбберләнсә, ул, киресенчә, җәһәннәм әһелләреннән булыр.

Аллаһ Тәгәлә аны яхшы, күркәм сүз дип атады. Аллаһ Тәгалә әйтә: "Ул сүз (ягъни Ләә иләәһә илләә Аллаһ) яхшы үскән агач кебек, аның тамырлары нык, ә ботаклары күккә үрелгән"(Ибраһим сүрәсе, 24 аять).

Шулай ук Аллаһ аны "ныклы, көчле сүз"дип атады. Аллаһ Тәгалә әйтә: "Иман китергән кешеләргә Аллаһ дөньяда вә ахирәттә сабит (ягъни нык) булган "Ләә иләәһә илләә Аллаһ" сүзе белән ярдәм итә, ә кәферләрне Аллаһ калдыра һәм алар туры юлдан адашалар һәм Аллаһ Үзе теләгәнчә хөкем кыла" (Ибраһим сүрәсе, 27 аять).

Һәм шулай ук Аллаһ аны тәкъва сүзе белән сыйфатлады һәм Үзенең бөек Китабында әйтте: "Һәм Аллаһ аларга тәкъва сүзен (ягъни Ләә Иләһә илләә Аллаһ сүзен) йөкләде..." (әл-Фатх сүрәсе, 26 аять).

Шулай ук Аллаһ аны "дәгъвәтул хак" дип, ягъни "хаклыкка өндәү" дип атады.

Аллаһ Тәгалә әйтә: "Аллаһка гына хак өндәү багышлана..." (әр-Рагыд сүрәсе, 14 аять).

Шулай ук Аллаһ аны "гурватулвуска", ягъни "ныклы аркан" дип атады.

Аллаһ Тәгалә әйтте: "Кем Аллаһка гына гыйбадәт кыла һәм башка затларга гыйбадәт кылуны калдыра, шул ныклы арканга ябышты" (Бәкара сүрәсе, 256 аять).

Һәм шулай ук бу тәүхид сүзләрен – "Ләә иләәһә илләә Аллаһ" башка күп бөек сыйфатлар белән сыйфатлады.

Әй, Аллаһның бәндәләре, ул "Ләә иләәһә илләә Аллаһ" кәлимәсен Аллаһның һәрбер илчесе, хак дингә чакырганда, иң беренче итеп өйрәтте һәм шушы сүзгә өндәде.

Һәм ул кәлимә – Аллаһның бәндәләренә иң бөек рәхмәте һәм нигъмәте. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә "ән-Нәхл" сүрәсен, аны шулай ук нигъмәт сүрәсе дип тә атыйлар, шушы кәлимә белән башлады һәм әйтте: "Аллаһ Тәгаләнең әмере килде, Аллаһның хөкемнәрен ашыктырмагыз. Аллаһ Тәгалә мөшрикләр сыйфатлы булган мәхлүклар сыйфатыннан пакь һәм олуг. Ул фәрештәләрне вәхи белән үзе теләгәнгә җибәрә. Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һичбер яраклы зат юк сүзе белән кешеләрне кисәтегез һәм тик Миннән генә куркыгыз" (ән-Нәхл сүрәсе, 1, 2 аять).

Нәкъ шушы сүзләрне Ибраһим галәйһиссәләм үзенең нәселенә мирас итеп калдырды. Аллаһ Тәгалә әйтте: "Ибраһим үзенең атасына һәм кавеменә әйтте: Мин сез гыйбадәт итә торган сыннарыгыздан бизүчемен һәм мин юктан бар итүче Аллаһка гына гыйбадәт кылам һәм Ул мине туры юлга күндерер. Һәм бу сүзләрне ул үзенең нәселенә калдырды, бәлки, алар туры юлга кайтырлар" (әз-Зухруф сүрәсе, 26-28 аять).

Әй Аллаһның коллары, безнең сөекле Пәйгамбәребез сөннәтендә шушы сүзләр фазыйләтенә багышланган бик күп хәдисләр килә. Шулар арасында Тирмизи җыентыгында булган ике хәдис. Пәйгамбәребез әйтте: "Иң хәерле зекер ул - Ләә Иләәһә илләә Аллаһ дип әйтү". Һәм: "Иң хәерле дога - ул Гарәфә көнендә кылынган дога. Ә мин һәм миңа хәтле килгән пәйгамбәрләрнең әйткән сүзләреннән иң хәерлесе ул - "Ләә Иләәһә илләә Аллаһ", ягъни (Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк), Ул берүзе һәм Аның тиңдәше юк, һәрнәрсә Аның мөлкәтендә һәм Аңа гына мактау һәм Ул һәр нәрсәгә кодрәтле".

Тагын да бу кәлимәнең югары дәрәҗәсен күрсәтә торган сыйфатлардан - ул аның үлчәүдә авыр булуы, чөнки безнең сөекле пәйгамбәребез әйтте: "Әгәр дә Ләә Иләәһә илләә Аллаһ кәлимәсен үлчәүнең бер ягына куйсалар, ә икенче ягына җиде кат күк һәм җирне куйсалар, һичшиксез, "Ләә Иләәһә илләә Аллаһ" кәлимәсе авыррак булыр иде".

Шулай ук хәдис тапшырыла. Бу хәдистә сөекле пәйгамбәребез әйтте: "Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә мөселманнардан булган бер ир-атны барча мәхлүклар алдына чыгарып бастырыр һәм аңа туксан тугыз гөнаһ дәфтәрен күрсәтер. Ул дәфтәрләрнең киңлеге офык киңлеге сыман булыр. Шуннан соң аңа әйтерләр: "Син бу дәфтәрләрдә язылган гөнаһларыңны танйысыңмы?" Ул әйтер:"Әлбәттә, йә Раббым, бөтенесен таныйм". Шуннан соң аннан: "Синең берәр нинди яхшы гамәлең бармы?"- дип сорарлар. Ул: "Юк", - дип әйтер. Шуннан Аллаһ аңа әйтер: "Син ялгышасың, чөнки синең бер яхшы гамәлең бар һәм бүген беркемгә дә золымлык кылынмаячак". Шуннан соң бер кечкенә генә кәгазь битен чыгарырлар. Анда болай дип язылган булыр: "Мин шәһадәт китерәм: Ләә Иләәһа илләә Аллаһ вә әннә Мөхәммәд рәсүлү Аллаһ". Аллаһ әйтер: "Бу кәгазьне үлчәүнең бер ягына куегыз", һәм кеше әйтер: "Ий Аллаһ, бу туксан тугыз китап белән чагыштырсаң, бу дәфтәр бите бик бәләкәй бит". Һәм аңа әйтелер: "Бүген сиңа золымлык кылынмаячак". Кәгазь битен үлчәүгә куйгач, аның авырлыгы шундый булыр, хәтта теге туксан тугыз гөнаһ дәфтәрен үлчәүдән чыгарып ташлар. Чөнки Аллаһның исеменнән бернәрсә дә саллырак була алмый".

Ий Аллаһның коллары, вәҗип булып тора Аллаһка шөкер итәргә, чөнки Аллаһ безне һәм бөтен ислам өммәтен бу кәлимәгә өйрәтте. Атаклы остазыбыз Суфйән ибн Гуяйнә, Аллаһ аңа рәхимле, булсын әйтте: "Аллаһның колларына иңгән иң зур нигъмәт - ул Ләә Иләәһа илләә Аллаһ дигән кәлимәсен аларга өйрәтүе".

Аллаһка бу бөек кәлимәне безгә өйрәткәне өчен һәм безне бу кәлимә буенча яшәүчеләрдән һәм гамәлләр кылучылар җөмләсеннән яратканы өчен безнең мактауларыбыз булсын! Мин Аллаһтан үзем өчен һәм сезнең өчен, кылган гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйм һәм сез дә гафу итүен сорагыз, чөнки Аллаһ гөнаһларны гафу итүче, Рәхимле.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

***Тырышлык әдәпләре***

* Һичнәрсәсе булмаган кеше – фәкыйрь түгел, бәлки һөнәре вә тырышлыгы булмаган кеше фәкыйрьдер

* Үзе хакында тырышкан кешегә эш һәрвакытта ярдәм итәр

* Тырыш кеше гүзәл тереклек иткән хәлдә. Ялкау кеше ачлыктан үләр. Бу дөнья тереклеге һәркемнең үз гайрәтенә тапшырылган. Шуның өчен дөньяда торыр вә көн кичерер өчен һичкемгә ышанып тормыйча, фәкать үз гайрәтегездән өмет итегез, вә үзегез өчен тырышыгыз

* Зирәк булган вакытыгызда – зирәклеккә ышанып яки һөнәрле булган вакытыгызда – һөнәргә арка биреп, эшсез вә хәрәкәтсез, тик ятмагыз. Чөнки тырышлык күренмәгән вә хәрәкәт ителмәгән хәлдә, зирәклек белән һөнәрдән бер файда хасил булмас

**Риза ФӘХРЕДДИН**

## СОРАУ-ҖАВАП

***Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.***

**Сорау.** Соңгы елларда мин простатит белән җәфаланам, бер намаз башкарганчы 2-3 мәртәбә кече хаҗәт белән тәһарәт бозыла, һава да чыга. 5-10 минут саен тәһарәт алмас өчен памперс куллана башладым. Бу тәһарәтне бозамы? Яңадан тәһарәт алып намазны дәвам итәргәме?

**Җавап.** Гозерле кеше (чире сәбәпле тәһарәте тормый, гел бозыла) фарыз намаз вакыты кергән саен бер тапкыр тәһарәт алса, икенче намаз вакыты кергәнче тәһарәтле санала, әгәр үз ихтыяры (теләге) белән тәһарәтен бозмаса. Памперска килгәндә, әгәр намаз саен аны алыштырырга мөмкинчелек булса – алыштырасыз, мөмкинчелек булмаган очракта – нәҗес кием белән намаз уку да дөрес була.

# Өметеңне өзмә

Аллаһ Тәгалә безне Үзенең Китабында өмет өзмәскә, төшенкелеккә бирелмәскә чакыра.

Мәсәлән, бер аятьтә шулай диелә: «Аллаһ рәхмәтенә өметегезне өзмәгез, тик кяферләр генә Аллаһ рәхмәтенә өметен өзә» («Йосыф» сүрәсе, 12:87). «Чынлап та, һәр авырлыктан соң җиңеллек килә!» – диелә икенче бер аятьтә («Җәелдерү» сүрәсе, 94:5). Төшенкелеккә бирелмәс өчен нәрсәләр эшләргә? Мөселманнар өчен түбәндәге киңәшләрне биреп була.

Аллаһка дога кылып тору. Мәсәлән, бер хәдисендә Аллаһ рәсүле (с.г.в.) шулай дигән: «Кем төшенкелеккә бирелә, шул сүзләрне әйтсен: "И Аллаһ, мин – Синең колың, Синең колларың булган ир белән хатынның улы. Минем язмышым – Синең кулыңда. Синең карарларың гадел һәм минем өчен зарури. Үз-үзеңне атаган, яки Китабыңда керткән, яки мәхлукларыңның берәрсенә ачкан, яки бөтенесеннән дә яшергән һәр гүзәл исемең аша Сиңа ялварам – Коръәнне йөрәгемнең язы, күкрәгемнең нуры һәм сагыш-зарларымнан котылу чарасы ит!»

Коръәнне еш уку, Аллаһны еш зикер итү.

Сабыр кешеләрне көткән бөек әҗер хакында үз-үзеңә хәтерләтеп тору.

Аллаһ Тәгалә Коръәндә: «Дөреслектә, сабыр иткәннәргә (Ахирәттә) әҗер-саваплары исәпсез-хисапсыз бирелер», – ди («Тәркемнәр» сүрәсе, 39:10).

Кешеләр белән мөгамәлә иткәндә йомшак һәм ачык булу.

Киләсе хәдисне истә тоту мөһим: «Тәмуг утына хәрәм булган кеше хакында әйтергәме? Ул – ярдәм кулы сузарга әзер, йомшак күңелле һәм игелек күрсәтергә атлыгып торучы кеше» (әт-Тирмизи).

**Дилбәр БУЛАТОВА әзерләде.**

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

Гарәп теленнән “мизан” сүзе “үлчәү” дип тәрҗемә ителә. Биредә кыямәт көнендә кешеләрнең гамәлләрен үлчи торган үлчәү турында сүз бара. Бу хакта “Әнбия” сүрәсенең 47 нче аятендә болай диелә: “Кыямәт көнендә Без гаделлек бизмәне корып куячакбыз. Ул көнне инде һичберкемгә нинди дә булса гаделсезлек кылынмас. (Кылган эшләрегезнең) гәрчич бөртеге кадәрлесен дә дөрес бизмәнгә салырбыз. Исәп-хисап өчен мин Үзем дә җитәрмен”. ( “Әнбия/Пәйгамбәрләр”, 21:47).

“Зүлзиләт” сүрәсенең 7, 8 нче аятьләрендә дә шундый мәгънәле фикер урын алган: “Кем тузан бөртеге кадәр генә игелек кылган булса да, ул күренер. Кем тузан бөртеге кадәр генә әшәкелек кылган булса, ул да күренер”. (“Зүлзиләт/Җир тетрәү”, 99:7-8).

Бу аятьләрне тәфсир кылучы галимнәр аңлатуы буенча, кәферләрнең яхшы гамәлләре бернинди әҗер-савапка ия булмас һәм аларга файда китермәс, чөнки ул гамәлләр Аллаһ ризалыгы өчен эшләнмәде. Шуңа күрә мизанны иман китергәннәр өчен генә куела торган үлчәү буларак аңларга кирәктер. “Аларның (Раббының аятьләрен вә Аның белән ахирәттә күрешәчәкләрен инкарь итүчеләрнең) гамәлләре заяга (әрәм) булачак һәм кыямәт көнендә (шул гамәлләрнең) бернинди дә авырлыгы булмас”. (“Кәһаф/Тау тишеге”, 18:105)

**(“Ислам дине нигезләре”нән)**

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

# Гакыйка корбаны

***Бездә бала туу хөрмәтенә, Аллаһка шөкер итү йөзеннән, гакыйка корбаны чалу гадәте яшәп килә. Корбанлыкны кайчан чалу дөрес, ул мәҗбүриме һәм аны бүлү тәртибе нинди? Казанның «Өметлеләр» мәчете имам хатыйбы Алмаз хәзрәт Сафин шулар турында сөйләде.***



*– Хәзрәт, гакыйка сүзе ул нәрсәне аңлата?*

*– Гакыйка – бала туганнан соң чалына торган корбан. Асылда «гакыйка» сүзе яңа туган баланың башындагы чәчен аңлата. Баланың чәчен шушы корбанны чалганнан соң алганга күрә, әлеге корбан да «гакыйка корбаны» дип аталган. Гакыйка корбанын чалып, мөселман кешесе Аллаһка шөкер итә һәм кешеләрне шушы шатлыклы вакыйга уңаеннан кунак итә. Гакыйка корбанын чалу турында Мөхәммәд пәйгамбәр шулай дип әйткән: «Һәрбер бала – гакыйка корбанының «тоткыны». Бу корбан аның исеменнән җиденче көнне чалына, шул көнне аңа исем кушыла һәм шул көнне чәче алына» (Тирмизи хәдисләр җыентыгы). Галимнәр аңлатуынча, гакыйка корбаны чалынган бала Кыямәт көнендә әти-әнисенә шәфәгать кыла ала. Шулай ук аның икенче файдасы да бар. Корбанны чалганнан соң, шайтан ул балага зарар эшли алмый. Башка бер галимнәр аңлатуынча, шушы корбанны чалу баланың сау-сәламәт үсүенә сәбәп булып тора. Аллаһ Тәгалә бу баланы гакыйка корбаны чалу бәрабәренә авырулардан, имгәнүләрдән һәм бәла-казалардан саклый.*

*– Җиденче көнне чалына, дидегез. Ә соңга калынса?*

*– Әгәр дә бу көнне чалып булмаса, башка көнне дә ярый. Кайбер галимнәр фикеренчә, бу корбанны чала торган көннәр бала туганнан соң 7, 14, 21нче көннәр. Гакыйка корбанын 7нче көнне чалганнан соң баланың чәчен алу сөннәт. Соңыннан ул чәчнең якынча авырлыгын билгеләп, көмеш бәясе белән сәдака бирергә кирәк. Мәсәлән, 1 гр көмеш хәзер 30 сум. Әгәр дә чәч авырлыгы 10 гр булса, 300 сум сәдака бирү сөннәт була.*

*– Гакыйка мәҗбүриме? Чалынмаган булса, гөнаһы юкмы?*

*– Мәҗбүри түгел. Хәнәфи мәзһәбендә аның хөкеме мөбәх, ягъни ихлас ният белән башкарсаң савап була, ә үтәмәсәң гөнаһ булмый. Әгәр дә мөселман кешесе бу корбанны чала икән, аңа әҗер-савап языла һәм ул Аллаһның ризалыгына ирешә вә Аның рәхмәтенә якыная.*

*– Әтисе урынына берәр туганы чалдыра аламы?*

*– Гадәттә, бу корбанны әти-¬әни үз акчаларына корбан сатып алып чалырга тиеш. Шулай ук, аларның рөхсәте белән, әби-бабалары да чалыр-га мөмкин. Мәсәлән, Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең оныклары Хәсән белән Хөсәен тугач, бу корбанны үзе чалган.*

**Әңгәмәдәш - Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА (“Шәһри Казан”).**

**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**

*“Ислам нуры” газетасы - мәгърифәт, аң-белем, дини тәрбия чарасы буларак, тиражы күп меңнәргә, миллионнарга артып, халкыбызны шатландырсын иде. Һәрбер мәчеттә сөйләрлек вәгазьләре, кешеләр тыңлап, гыйбрәт алырлык тапкыр сүзләре һәркем күңеленә хуш килерлек. Уңышлар, сәламәтлек, тормышыгызда дөнья һәм ахирәт бәхете теләп калам.*

## Укыйк әле...

*Ислам нуры газетасы*
*Таралсын һәрбер өйгә.*
*Бу газетаны укыгач,*
*Күңелләргә нур иңә.*

*Галимнәрнең язмаларын*
*Укыйк әле шатланып.*
*Вакыт табып, үзең дә яз!*
*Укысыннар таң калып.*

*Ихлас күңел белән ярат,*
*Иманлы булып яшик.*
*Гафият йокысыннан уяныл,*
*Яшеннәр булып яшьник.*

*Бушка уздырмыйк гомерне,*
*Яшь вакытта бигрәк тә.*
*Изге гамәл кылган яшьләр*
*Юл салалар җәннәткә.*

*Иман нуры балкып торсын*
*Еракларадан күренеп.*
*Үс үрелеп югарыга,*
*Үрмә гөлдәй үрелеп.*

*Гыйлем алыйк, укыйк әле,*
*Укыйк әле һәркөнне.*
*“Ислам нуры” газетасы*
*Соклаңдырсын һәркемне.*

**Тәзкирә АЛЯКИМОВА,**
**Нурлат районы, Түбән Норлат авылы.**

**РУХИ ХӘЗИНӘ**

## Без – Мөхәммәд өммәте

Мөхәммәд (саллалаһү галәйһи вәссәләмне) намуслы, дөрес сүзле, күркәм холыклы булганы өчен, пәйгамбәрлек иңгәнче үк, бар Мәккә халкы “Әл-Әмин”, ягъни иң ышанычлы дип йөрткән. Ни өчен соң 40 яшендә, Мөхәммәд галәйһиссәләмгә пәйгамбәрлек вазыйфасы бирелгәч, Мәккә халкының күпчелеге аны кире каккан, кабул итмәгән? - Бәлки, алар үзләре табына торган потларга нык күнеккән булганнардыр. Шуңа ул гадәтләреннән арына алмаганнар. Кеше берәр нәрсәгә күнексә, аны ташлавы авыр бит. Ә, бәлки, ата-бабаларының ялгыш дине аларның акылларын томалагандыр, шуңа Аллаһтан иңгән хак сүзне ишетергә теләмәгәннәрдер... 40 яшенә кадәр югары әхлаклы, гадел, дөрес сүзле булып яшәгән кеше, әлбәттә, Аллаһка, иманга кагылышлы җитди нәрсәдә алдый алмый, бу көн кебек ачык. Бервакыт РасүлАллаһ, Сафа калкулыгына менеп, Мәккә халкына мондый сүзләр белән мөрәҗәгать иткән: “Әйтегез әле, әгәр дә мин сезгә тау артында сезне таларга килгән атлы гаскәр тора, дисәм, сез ышанырсызмы миңа?” Кешеләр: “Әйе, ышанырбыз! Син Әл-Әмин”, – дигәннәр. Шунда РасүлАллаһ: “Үзегезне тәмуг газабыннан саклагыз. Мин сезгә кисәтүче булып килдем”, - дигән. Ягъни башка барлык сүзләренә дә тулы ышаныч белдергәч, аның Пәйгамбәр булуына да ышануларын сораган. Ләкин, чыннан да, ата-бабадан калган динне яки гореф-гадәтләрне, ялгыш булсалар да, калдыруы авыр. Мәккә халкының бер өлеше нәкъ шул сәбәпле Мөхәммәд галәйһиссәләмне беренче пәйгамбәрлек елларында кабул итә алмаган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм заманында бар гарәп ярымутравыннан Кәгъбә янына гыйбадәт кылыр өчен, бик күп кешеләр җыела торган булган. Кәгъбәдә өч йөздән артык пот торган. Шушы потларга табынырга килгән кешеләргә кораеш кабиләсе үзен кунакчыл хуҗа итеп күрсәткән, шулай итеп аларның дәрәҗәләре үскән. Сату-алу эшләре дә хаҗ вакытында гөрләп барган. Болар барысы да кораеш кабиләсенә башкалар тарафыннан олы ихтирам уяткан һәм зур матди табышлар китергән. Сөекле Пәйгамбәребез (галәйһиссәләм) потларга каршы чыгып, бер Аллаһка гына гыйбадәт итәргә чакыргач, кабилә башлыклары шушы хөрмәтне, зур керемнәрне югалтырбыз дип куркып калганнар. Бу да сәбәпләрнең берсе. Ислам бар кешеләрне – байларны да, хезмәтче-колларны да - тигез итеп игълан иткән, бер дәрәҗәгә куйган. Ул да Пәйгамбәребез галәйһиссәләм өйрәткәннәргә каршы чыгарга сәбәп булгандыр. Бер кешене икенче кешедән өстен итүче сыйфат - бары тик тәкъвалык, дигән РасүлАллаһ (галәйһиссәләм). Тән төсе дә, милләт тә, ата-бабаларның нинди нәселдән булуы да, туплаган байлык та беребезгә дә үзебезне башкалардан өстен чыгарырга сәбәп була алмый. Бары тик тәкъвалык, җанның Аллаһка якын булуы мөһим. Әлбәттә, мондый фикерләр колбиләүчелектән рәхәт күреп, затлы нәселләре белән тәкәбберләнеп яшәгән кораеш кабиләсе җитәкчеләренә ошамаган. Шуңа күрә алар, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең дөрес сүзле булуын белсәләр да, аңа каршы килгәннәр, ул алып килгән диннең җәелүен теләмәгәннәр. Ә Мәккәнең гади халкы һәм коллары, киресенчә, исламның гаделлеген күреп, күпләп-күпләп мөселман булганнар. Һәм шуның аркасында хуҗаларыннан, көчле нәселләрдән авыр газаплар күргәннәр, хәтта үтерелгәннәр.

Әбү Җәһил – мөселманнарның иң мәрхәмәтсез дошманы. Шуңа аны “караңгылыкның атасы”, ягъни Әбү Җәһил дип йөрткәннәр дә. Иң беренче мөселманнарны да интектереп ул үтергән. Ә Әбү Суфьян башта потка табынучы булган, аннан күп еллар үткәч кенә, исламны кабул иткән. Икесе дә мөшрикләрнең, ягъни потка табынучыларның җитәкчеләре булган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә аятьләр иңгәч, ул аларны халыкка җиткерә торган булган. Аллаһ сүзләрен мөшрик җитәкчеләре дә ишеткән. Һәм аларга да Коръән аятьләре көчле тәэсир ясаган, алар бу сүзләрнең гади кеше сүзләре дә, шагыйрь сүзләре дә булмавын аңлаганнар. Һәм халык та бу тәэсиргә бирешмәсен өчен, алар Мөхәммәд галәйһиссәләмне сихерче дип игълан иткәннәр. Ислам тарихында шундый вакыйга булган. Бер төнне Әбү Суфьян, Әбү Җәһил һәм Әхнәс ибн Шәрийк исемле тагын бер мөшрик, бер-берсенә белдермичә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм өе янына җыелып, аның төнге намазда Коръән укыганын тыңлап утырганнар. Таң алдыннан таралышканда, алар бер-берсен күреп алганнар һәм эшнең нәрсәдә икәнен белеп, бер-берсен гаепли башлаганнар. Башка монда килмәскә сүз куешканнар. Ләкин бу хәл 3 көн дәвам иткән. Шуннан соң гына, кешеләр күрмәсен, шикләре уянмасын дип, Коръәнне яшерен тыңлау гадәтеннән ваз кичкәннәр. Һәм беркөнне Әхнәс ибн Шәрийк Әбү Җәһилдән: “Мөхәммәд укыганнар турында ни уйлыйсың?” – дип сораган. Әбү Җәһил: “Без Мөхәммәднең нәселен гел уздырырга теләп яшәдек. Алардан чыккан Пәйгамбәрне кабул итмәячәкбез”, – дигән. Ягъни кайбер нәселләр тәкәбберлек, дан ярату аркасында гына РасүлАллаһтан йөз чөергәннәр.

Без – Мөхәммәд өммәте. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләмне олылап, аның турында күбрәк белү нияте белән, бергәләп, бердәм өммәт булып яшик.

**Язманы “Хәзинә” клубы мөгаллимәсе Әлфия МӨДӘРИСОВА әзерләде.**

## Һәр ялтыраган алтын түгел

*Әти-әниләр барыбыз да балаларыбызның бәхетле булуын телибез. Алар бәхетле булсын дисәк, иң элек балаларыбызга ислам тәрбиясе биреп, аларны хак мөселманнар итеп үстерик. Аларга дөрес тәрбия бирә алсак, иманлы, намазлы итеп үстерсәк, хәрам ашатмасак, күп проблемаларыбыз үзеннән-үзе бетәр. Без вәгазьдә: "Балаларыбызның катнаш никахына булдыра алган кадәр каршы торыгыз, ризалык бирмәгез," – дигәч, бер ханым: "Әгәр яратса?" – дип сорау бирде. Мин: "Ирең әчәргә яратамы? Яратса, көн саен әчәргә дип акча бирәсеңме?" – дип сорадым. Ул хатын: "Ярата дип, эчәргә акча бирергә мин тиле түгел бит", – диде. Димәк, һәр ялтыраган хәерлегә илтми.*

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстанның баш казые.**

## Гасырлар хикмәте

*(Ислам галимнәренең хикмәтле гыйбарәләре)*

Башкалар үзләрен тышкы яктан бизәгән чакта, син үзеңне эчке яктан бизә. Бөтенесе башкаларның хаталарын барлап торганда, син үз хаталарың хакында уйлан. (Руми).

Синә килгән бәла-казаны ничек бар шулай кабул итсәң, синең каршыңда күк капусы ачылыр һәм күңел күге яктырып, авыр хәлдән чыгу юлы күренер... (Руми).

Гади кешегә таш булып күренгән нәрсә гыйлем иясе өчен энҗеләрдәй олуг хәзинәдер. (Руми).

Бу дөньяга нәфес теләге илә карама: еланның аркасы бизәкле, матур, ләкин аның агуы үлемгә дучар итәргә мөмкин. (Руми).

Әгәр нәрсә әйткәнеңне анык белсәң, синең сөйләмең бәһасез. Әйтәсе сүзләреңне авызыңнан чыгарганчы, аларны йөрәгең бизмәнендә үлчә. (Кәбир).

Берәү Баязид ишегенә шакыгач, ул: "Син кемне эзлисең?" – дип кычкырып сорады. Ишек шакучы: "Баязидне!" – дип әйткәч, Баязид: "Мин дә аны инде 30 елга якын эзлим, әмма уңышка әле ирешә алмадым", – дип җавап бирде ди... (Зун-Нүн әл-Мисри).

Акылыңны нәрсә белән тутырганыңа бик җаваплы кара: нәкъ шушы нәрсәләр белән синең тормышың тулачак. (Локман Хәким).

**Ришат КУРАМШИН әзерләде, Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

## Ни өчен?

Бер акыл иясеннән сораганнар:

- Ни өчен ярлылар ачык йөзле була, ә минем байлар, киресенчә, кырыс йөзле?

- Тәрәзәгә кара әле, ни күрәсең?

- Балалар туп тибә.

- Ә хәзер көзгегә кара. Анда ни күрәсең?

- Үземне.

- Менә күрәсеңме, алар икесе дә пыяладан ясалган - көзге дә, тәрәзә дә, тик берсенә әз генә көмеш кургаш кушсаң, аннан бары үзеңне генә күрә башлыйсың, - дип җавап биргән акыл иясе.

*Балалар өчен*



## Коръән Кәрим

Сөекле балам, тыңла,
Уйла һәм фикерләп кара!
Ул нинди китап була,
Җаваплар бар сорауларга?!
Ул китапны тотканда,
Бел, бардыр әдәбе, аңла!
Таһарәтсез кагылма,
Түбән җирләргә куйма!
Сөекле балам, уйла,
Укы син аны һәркайда!
Өстенә әйбер куйма,
Кыйммәтле китап, син аңла!
Яңа ачыш ача гел,
Андый китап башка юк, бел!
Безгә карата гадел,
Гади китаплардан түгел!
Сорауларга җавапны
Шул китаптан укыйсы.
Көннәр түгел, гомер буе
Шуннан белем туплыйсы.

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА, "Асыл зат" төркеме җитәкчесе.**

**Саулыгым – байлыгым**

## Бәбкә үләне



Бәбкә үләнендә организмга файдалы булган матдәләр бик күп. Аның яшел йомшак яфракларын ашыйлар, ашын да пешерәләр. Салат та ясарга мөмкин. Ә төнәтмәсен аналык юлында җәрәхәт булганда кан туктатуда кулланалар. Хатын-кызларның җенес юллары ялкынсынганда, күкәйлек юлларына салкын тигәндә, аналыкта шеш булганда да файдасы бар. Ашказаны, бавыр, бөер, үт һәм сидек куыгы авыруларыннан; ютәлдән, сулыш буылудан (астма), туберкулездан дәвалау өчен дә киң кулланалар. Үләнне чәчәк ата башлагач җыю максатка ярашлы. Киптереп куйган бәбкә үләнен өч ел кулланырга була. Бәбкә үләненең төнәтмәсен болай эшлиләр: бер аш кашыгы вакланган бәбкә үләнен бер стакан җылымса суга салып, ярты сәгать сулы «мунча» ясап кайнатасың. Унбиш минут төнәткәннән соң сөзәсең. Көнгә өч-дүрт тапкыр берәр аш кашыгы эчәсең.

**Тәмле булсын!**

## Гөмбәле самса



Самса эченә гадәттә вак итеп туралган сарык һәм сыер ите салалар, гөмбә белән дә пешерәләр.

Камыр өчен 1 стакан кайнап суынган су, 1 йомырка, бер чеметем тоз, чама белән он алына. Камырны майлау өчен 100 грамм атланмай, ә әзер самсаның өстен майлау өчен бер йомырка сарысы кирәк булачак. Эчлек өчен 500 г гөмбә, 2 эре суган, тоз, борыч; кыздыру өчен - үсемлек мае.

Эш барышы: камыр басарга, токмач камыры кебек җәяргә, эретелгән май белән майларга һәм камыр җәймәсен рулет кебек төрергә, азык пленкасы белән капларга, 30-40 минутка суыткычка куярга. Эчлек өчен гөмбәне һәм суганны вак кына турап, тоз-борыч өстәп, кыздырып алырга. Аннары камырны суыткычтан алырга, ике бармак чамасы кисәкләргә бүләргә, бик юка итми генә җәяргә, өчпочмак сыман ясарга. Майлы табага бөргән өске ягын аска каратып тезәргә дә өстенә бер йомырканы сарысын туглап сөртәргә, кончет орлыгы сибәргә. 20-30 минут пешә.

**(Гөлүзә Василовадан алынды.)**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**график буенча**
**фактта 23 август 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**